**«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 ел, №25-ФЗ Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 25.06.2013 ел, №50-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Тәтеш муниципаль районы Советы Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрүне тәртипкә салу максатларында, Тәтеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне яңа редакциядә расларга (бирелә).

2. Тәтеш муниципаль районы Советының 27.10.2011 №10-15 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне Тәтеш муниципаль районы башлыгы урынбасары Е.Г. Курковка йөкләргә.

Тәтеш муниципаль районы

башлыгы Р. Х. Сафиуллов